ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «01» апрель 2019г.** **№ 46**

**Арча район Советына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибен раслау турында**

2003 елның 11 апрелендәге «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында»гы 16-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 маддәсе нигезендә **КАРАР БИРӘМ**:

1. Арча район Советына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау Тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) бастырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советы аппараты җитәкчесе Р.Н.Галимуллинга йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы И.Г.Нуриев

АРСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АРЧА РАЙОН СОВЕТЫ

Расланды
Арча муниципаль районы
Башлыгының 2019 елның
«01» апрель
46 номерлы карары белән

**Арча район Советына**
**гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау**
**Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип 2003 елның 12 маендагы «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында»гы 16-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 маддәсен үтәү максатында эшләнде һәм Арча район Советына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне (алга таба – мөрәҗәгатьләр) гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Арча район Советына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тиешле вакыт аралыгында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен, шул исәптән язма рәвештә, электрон хәбәр формасында, шулай ук Интернет-кабул итү аркылы, гражданнарны шәхси кабул итү вакытында һәм телефон аша кергән мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып башкарыла.

3. Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау елга ике тапкыр башкарыла: яртыеллык буенча һәм узган ел буенча.

4. Һәр яртыеллык нәтиҗәләре буенча Арча район Советына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау өчен җаваплы зат кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерә.

5. Анализ үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

- кергән, башка кешегә җибәрелгән һәм каралган мөрәҗәгатьләр, шул исәптән, электрон документ формасында кергән мөрәҗәгатьләрне дә кертеп, телдән һәм язма мөрәҗәгатьләр саны;
- мөрәҗәгатьләрнең төзелеше һәм темасы;
- шәхси кабул итү оештыру өчен җаваплы затлар тарафыннан шәхси кабул итү вакытында кабул ителгән гражданнар саны;
- мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар (андыйлар булган очракта) турында.

6. Гражданнар мөрәҗәгатьләренең гомуми анализы елга ике тапкыр Арча муниципаль районы рәсми сайтына (http://arsk.tatarstan.ru/) урнаштырыла.